ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.04.2022 г.Лениногорск № 290

2021 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү методикасы нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта бирелә торган исәпләү методикасы нигезендә билгеләргә:

2022 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү нормасы буенча торак урыннары алу базар хакының иң чик күрсәткече:

ялгыз яшәүче гражданин өчен – 910 437,00 сум;

ике кешедән торган гаилә өчен – 1 158 738,00 сум;

өч кешедән торган гаилә өчен – 1 489 806,0 сум.

2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме СЖОнын исәп-хисап күрсәткеченә тигез итеп кабул ителә.

3. 2022 елга граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме:

ялгыз яшәүче гражданин өчен – 26 602 сум;

ике кешедән торган гаилә өчен – 16 928 сум;

өч кешедән торган гаилә өчен – 14 510 сум.

4. Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорскские вести» газетасында бастырып чыгарырга һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары В.В. Друкка йөкләргә.

Җитәкче З.Г. Михайлова

Л.В.Лапицкая
5-13-74

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 1 апрелендәге 290 номерлы карарына кушымта

**Исәпләү методикасы**

1. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен исәпләү формуласы:

**СЖ = НП х РС х РЦ, кайда:**

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

НП - муниципаль берәмлектә торак урыны бирү нормасы:

гаиләнең бер әгъзасына 18 $м^2$;

ялгыз яшәүче гражданин өчен 33 $м^2$ дан артык түгел;

ике кешедән торган гаилә өчен 42 $м^2$ дан ким түгел.

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан раслана торган Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны мәйданының бер квадрат метрының уртача исәп-хисап бәясе.

«Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2022 елның 12 февралендәге 54 номерлы «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлыгы хаты нигезендә, Лениногорск муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе 2021 елда 27 589 сум тәшкил итә.

а) ялгыз яшәүче кеше өчен (сум):

СЖ= 33*27 589 = 910 437,00

б) ике кешедән торган гаилә өчен (сум):

СЖ= 42*27 589 = 1 158 738,00

в) гаиләгә өч һәм аннан да күбрәк кеше (сум):

СЖ= 18*27 589*3 = 1 489 806,0

2. 2020 елга граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме формула буенча билгеләнә:

**ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 – [ (1 + ПС) $^{-КП}$ ] )/ (0,25 х РС), где:**

ПД - гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урыны алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең иң чик күрсәткече;

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

ПС - кредит буенча бер айга процент ставкасы (еллык 9,5%/100/12 ай);

КП – кредит срогы буена кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (180 ай);

РС – гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы һәм фатир бәясенең чагыштырмасы;

0,25 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык кереме белән чагыштырмасы.

а) ялгыз яшәүче кеше өчен (сум):

$0{,}7 \times 910\,437{,}00 \times 0{,}00791 / (1 - [(1+0{,}00791)^{-180}]) / (0{,}25 \times 1) = 26\,602$ сум

б) ике кешедән торган гаиләгә (сум):

$0{,}7 \times 1\,158\,738{,}00 \times 0{,}00791 / (1 - [(1+0{,}00791)^{-180}]) / (0{,}25 \times 2) = 16\,928$ сум

в) өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә (сум):

$0{,}7 \times 1\,489\,806{,}00 \times 0{,}00791 / (1 - [(1+0{,}00791)^{-180}]) / (0{,}25 \times 3) = 14\,510$ сум

---